КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 сентябрь г.Казань № 1044

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 25 май, 368 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 25 май, 368 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 июль, 516 нчы; 2016 ел, 7 октябрь, 720 нче; 2017 ел, 25 май, 299 нчы; 2020 ел, 18 июль, 605 нче; 2021 ел, 31 май, 424 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына» сүзләреннән соң «һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына» сүзләреннән соң «һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә кече һәм урта

эшмәкәрлек субъектларына һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибендә:

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Грант бирү нәтиҗәләре:

грант алучы физик затлар өчен:

продукция җитештерү һәм сату күләмен кимендә 10 процентка арттыру;

продукциянең үзкыйммәтен кимендә 15 процентка киметү;

җитештерүне кимендә 10 процентка модернизацияләү;

грант алучы эшмәкәрлек субъектлары өчен:

продукция җитештерү һәм сату күләмен кимендә 10 процентка арттыру;

продукциянең үзкыйммәтен кимендә 15 процентка киметү;

җитештерүне кимендә 10 процентка модернизацияләү;

яңа эш урыннары булдыру:

500,0 мең сум күләмендә грант биргәндә – кимендә 10 берәмлеккә;

400,0 мең сум күләмендә грант биргәндә – кимендә биш берәмлеккә;

300,0 мең сум күләмендә грант биргәндә – кимендә өч берәмлеккә;

күргәзмә-сатуларда катнашу санын кимендә 10 процентка арттыру.

Грант бирү нәтиҗәләренә ирешү срогы – грант бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, Министрлык тарафыннан бу Тәртипнең 6.2 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән очракта, килешүдә билгеләнә торган грант бирү нәтиҗәләренә ирешү сроклары грант бирелгән елдан соң килә торган елның 31 декабреннән дә соңрак билгеләнә алмый.»;

1.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.10. Министрлык, сайлап алу башлана торган датага кадәр 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, Бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://mincult.tatarstan.ru) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) һәм Системада, түбәндәгеләр турында мәгълүмат күрсәтеп, конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү хакында белдерүләр урнаштыруны тәэмин итә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасы (әлеге дата конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

бу Тәртипнең 1.7 пункты нигезендә грант бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

бу Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә грант алырга теләүчеләргә карата таләпләр һәм грант алырга теләүчеләр тарафыннан әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

грант алырга теләүчеләр тарафыннан заявкалар бирү тәртибе һәм бу Тәртипнең 4.2 – 4.6 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләр билгеләнә торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

бу Тәртипнең 4.12 – 4.19 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

грант алырга теләүчеләргә сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләрен аңлату тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан килешүгә кул куелырга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

Бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң була алмаган сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.»;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Грант алу хокукына конкурс комиссиясе тарафыннан сайлап алу йомгаклары буенча билгеләнгән һәм түбәндәге критерийларга туры килә торган грант алучылар ия:

грант алучы үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

проектны тормышка ашыру чыгымнарының гомуми суммасыннан кимендә 15 процент күләмендә аны финанслашуны тәэмин итү.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Грант алырга теләүчеләр сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1енче көненә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

грант алырга теләүченең салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаска тиеш;

грант алырга теләүченең субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнәмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычы булмаска тиеш;

грант алырга теләүче юридик затлар үзгәртеп оештыру (грант алырга теләүче юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаска тиеш, аларга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәскә, грант алырга теләүченең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаска, ә грант алырга теләүче индивидуаль эшмәкәрләр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмаска тиеш;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында юридик зат булып торган грант алырга теләүченең дисквалификацияләнгән җитәкчесе, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки баш бухгалтеры (баш бухгалтеры булганда) турында, индивидуаль

эшмәкәр (индивидуаль эшмәкәр булып торган грант алырга теләүче өчен) турында мәгълүматлар булмаска тиеш;

грант алырга теләүчеләр чит ил юридик затлары, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә һәм (яки) финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачу һәм бирү каралмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аларның теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артып киткән Россия юридик затлары булмаска тиеш;

грант алырга теләүчеләр бу Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаска тиеш;

грант алырга теләүчеләр экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.3 пункт өстәргә:

«2.3. Грант алырга теләүчеләр түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә бу Тәртипнең 1.7 пунктында күрсәтелгән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле бер елдан ким булмаган тәҗрибә булу;

бу Тәртипнең 1.7 пунктында күрсәтелгән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле кадрлар составы булу;

бу Тәртипнең 1.7 пунктында күрсәтелгән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле матди-техник база булу.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Сайлап алуда катнашу өчен грант алырга теләүче бу Тәртипнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча электрон рәвештә йә кәгазьдә заявка һәм документлар тапшыра.

Бу Тәртипнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча электрон рәвештә заявка һәм документлар тапшыру өчен грант алырга теләүче Системада заявка формалаштыра, әлеге заявка шул исәптән үз эченә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә грант алырга теләүче, аның тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүмат, грант алырга теләүче турында тиешле сайлап алуга бәйле башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыкны ала, шул исәптән Системада бу Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча проектны тормышка ашыру чыгымнарының гомуми суммасыннан кимендә 15 процент күләмендә үз акчасы исәбеннән аны финанслашу турында гарантия хаты формалаштырыла, шулай ук реквизитлары машина ярдәмендә танып белenә торган итеп сканерлау яки фотога төшерү юлы белән электрон формага үзгәртелгән түбәндәге кәгазьдәге документларны терки:

грант алырга теләүченең бу Тәртипнең 2.2 һәм 2.3 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында вәкаләтле орган тарафыннан расланган белешмә кәгазе һәм документлар;

әгәр грант алырга теләүче юридик зат булса, грант алырга теләүченең уставы;

халык сәнгать һөнәрләренең тиешле материаллардан эшләнгән әйберләренең фотосурәтләре;

финанс-икътисадый нигезләү белән бу Тәртипнең 3 нче кушымтасында бирелгән форма буенча проект чыгымнары сметасы;

грант алырга теләүченең бу Тәртипнең 4 нче кушымтасында бирелгән форма буенча анкетасы;

бу Тәртипнең 5 нче кушымтасында бирелгән форма буенча проект паспорты;

бу Тәртипкә 6 нчы кушымтасында бирелгән форма буенча проектны тормышка ашыруның календарь планы;

Министрлык тарафыннан раслана торган форма буенча шәхси мәгълүматларны (физик зат өчен) эшкәртүгә ризалык.»;

4.4 пунктта:

өченче абзацта «2.2 пунктында билгеләнгән» сүзләрен «2.2 һәм 2.3 пунктларында билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

5.2 пунктта:

бишенче абзацта татар текстында «нәтиҗәләренә ирешү» сүзләрен «нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «максатлар,» сүзен төшереп калдырырга;

унберенче абзацта «һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан грант бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлешенә» сүзләрен «Министрлык тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәлешенә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан грант алучының Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә грант бирү тәртибен һәм шартларын үтәвенә тикшерү» сүзләренә алмаштырырга;

6.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Грант алучы Министрлыкка, хисап елының I – III кварталлары өчен – хисап кварталыннан соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, хисап елының IV кварталы өчен – хисап кварталыннан соң килә торган елның 10 февраленнән дә соңга калмыйча, килешүләрнең (шартнамәләрнең) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формаларына теркәлә торган формалар буенча, арта бара торган йомгак белән формалаштырып, грант бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып грант торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.»;

6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Министрлык грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне башкара.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Грант бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешүдән һәм грант бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

6.4 пунктта «максатлар, шартлар» сүзләрен «шартлар һәм тәртип» сүзләренә

алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләрен «дәүләт финанс контроле органнары» сүзләренә алмаштырырга;

6.6 пунктта «, максатлары» сүзен төшереп калдырырга.

2. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктның кырык өченче, җитмеш сигезенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин